**СОВЕТ**
**ПЕТРОПАВЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Ленина, д. 33
с.Слобода Петропавловская,423198

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ПЕТРОПАВЕЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 33
Петропавловка бистәсе авылы ,423198

тел.: (8-4348) 3-35-41, факс: (8-4348) 3-35-18.Ppav.Nsm@tatar.ru

# КАРАР
## Петропавел авыл җирлеге Советы
## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы

2016 елның 28 январендәге № 7-21

**Петропавел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Петропавел авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына ярашлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы, Петропавел авыл җирлеге башлыгының «референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 19 гыйнварындагы 2 номерлы карары нигезендә , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 25 гыйнварындагы 7-18 номерлы карары, Петропавел авыл җирлеге Советы карар итә:

1. 2016 елның 20 мартына Петропавловск авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2016 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, Петропавел авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма бер ел һәм аннан да күбрәк яшәмәгән затлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә:

авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны тоту;

авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урам яктыртуын ремонтлау;

авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә күпер юлларын ремонтлау;

янгын гидрантларын ремонтлау, авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен мотопомпа һәм янгын сүндерү култыклары сатып алу;

халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү, шул исәптән Андреевка авылындагы чишмәне ремонтлау һәм төзекләндерү.

"ӘЙЕ" ЮК.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә район газетасы «Шешминская Новь» да бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Петропавел авыл җирлеге башлыгы С.П.Дворецкая